ISSN 0868-4545

Балалар журналы


Салават күпере















Мин – әкият малае,
Ә син әкият кызы.
Сөйлим сиңа, тыңлап тор –
Чын «Әкият»нең үзендә
Булып кайтты Сыбызгы.

Урман әкияте

Син беләсеңдер инде! Ишеткәнсең, укыгансыңдыр: без барыбыз да – Әкият балалары. Кешеләрнең тормышы әкияттән башланып киткән. Бар кеше дә, шул ук космонавт та, президент, язучы, галимнәр, алтын куллы эшчеләр, тынгы белмәс авыл кешеләре... Әкият балалары алар.

«Җир йөзендә әкият бар!» – дип җырлана. Әйе шул, бар ул әкият! Казанда да, син яшәгән авылда да, Азнакай, Актанышта, кыскасы, бар җиһанда әкият бар!

Тукай да – әкият малае. Пушкин да әкият тыңлап үскән.

Барын бар да... ләкин кайларда икән соң ул әкият? Кайларда йөри икән?



«Укытты бүре сабак» (Т.Миңнуллин пьесасы).

Борын-борын заманда... хәер алай түгел, әле менә кичә генә Сыбызгы Казан урамнары буйлап чыгып китте. Әкият эзләп инде, әлбәттә.

Һәм ул бер яңалык ишеткән! Казан артындагы бер кара урманда Аю патша җыелыш җыйган. Әлеге җыенда бар урман җәнлек-киекләре, кош-кортлары катнашкан. Еланнар да килгәннәр.

– Җитте сезгә! – дигән Аю патша. – Безгә болай талашып яшәргә ярамый! Төлке куян куа, бүреләр пошиларны эзәрлекли! Бу хәлгә чик куярга кирәк!

– Дуслашырга кирәк безгә, әйе бит! – дип сүз кыстырган хәйләкәр Төлке.

– Ә ничек, ничек? – дип кызыксынган кылый Куян.



Директор Роза апа Яппарова.

– Әкият директорыннан сорыйк, – дигән Поши.

– Кит аннан! Әкиятнең директоры буламыни ул!

– Була! – дигән Поши! – Әнә, рәсемен күреп торасыз бит: Роза апагыз Яппарова!

Төлке тагын сүз кыстырган:

– Куян белән без төлке халкын дуслаштыручы кеше белән дә таныш булыгыз.

Кешеләр теләндә режиссер дип атала. Әнә бит фоторәсеме – Илдус абый Зиннуров!

– Куян, Илдус абый баш режиссермы?

– Кит, надан! Мәгънәсез сорау бирмә әле! Режиссер булгач башлы була инде ул!



Баш режиссер Илдус абый Зиннуров.

Аю боларны тыңлап-тыңлап торган да түзә алмаган:

– Менә тагын талашырга керештегез. Миндә зур яңалык бар!

Куян баласы:

– Әкиятнең рәссамнәр дигән кешеләре дә була икән! – дигән.



Баш рәссам Валентина Губская.





Рәссам Александр Губский.

Әнкә куян каты итеп аның койрыгыннан тартты, тик утыр янәсе. Ә койрык шарт итеп өзелде. Шуннан бирле куяннарның койрыклары кыска калган ди, имеш. Менә монысы да кечкенә генә әкият булды.

Аю патша һәммәсенә әмер бирде:

– Барыгыз да агачларга тотыныгыз! Яңалыкны ишеткәч, егылып китүегез бар!

– Син дә агач башыннан төш! – диде Төлке Тиен малаена.

– Игътибар! Игътибар! Яңалык! Тыңлагыз! Ишетегез! Белегез! Өр-яңа яңалык!

– Мин бүген, – дип сүзен башлады Аю патша, – төне буе меңьяшәр карт имән белән сөйләштем!

– Карт имән!? – диешеп шаккатты барысы.

– Карт имән телгә килгәнмени!

– Ай-яй! Мең еллык карт имән! Нәрсә диде соң ул?

– Урман бетә! – диде. – Агачлар корый! Озакламый урман буш далага әйләнеп калачак!

Җыендагылар кайгырышып елаша башладылар.

– Урмансыз без нишләрбез соң! – диде Бүре малае күз яшьләрен агыза-агыза.

– Моңа без үзебез гаепле, – диде Аю патша. – Мәсәлән, бүреләр гаепле.

– Бүреләр?!

– Әйе, әйе, нәкъ бүре, төлке ише җанварлар гаепле! Чөнки сез бер-берегез белән дус-тату яшәмисез! Урман–йортта тынычлык, дуслык бетте!

– Нишләп алай булсын! – дип каршы төште Карт бүре. – Урманны без түгел, ике аяклы бүреләр корыта, агачларны да шулар кисә! Таптый, сындыра!

Аю патша тамагын кырып куйды.

– Әйе, әйе, чөнки тынычлык, дуслык булмаган йортка афәт килүчән! Урман йортта татулык бетүне читтәгеләр күзәтеп кенә тора. Һәм алар һөҗүмгә дә күчә!

– Безгә нишләргә соң, Аю патша?

– Дуслашырга! – дип кырт кисте Аю.

Бүренең күзләре маңгаена менде:

– Нәрсә, мин Куян белән яки Эт белән дуслашырга тиешме хәзер! Юк, юк!

Аю аңа кырын күзе белән генә карап куйды да:

– Казан дигән калада «Әкият» бар. Андагы барлык җәнлек-җанварлар үзара дус яши! Безгә шулардан үрнәк алырга кирәк.

– Аю Агай, Аю агай, теге ниме, «Әкият» дип аталган курчак театрымы ул?

– Әйе! – диде Аю. – Сез, Төлкебикә белән Куянкай, бүген үк юлга чыгасыз! Казан каласына! Һәм анда «Әкият» театрын эзләп табасыз!





Татар дәүләт «Әкият» курчак театры бинасы.



Куян:

– Юлга?! Бүген үк?

Төлке:

– Куян беләнме?

Аю:

– Әйе. Җитәкләшеп!

Куян:

– «Әкият»не ничек табарбыз соң без ?

Аю патша:

– Сыбызгы ярдәм итәр!

Төлке:

– Милиционермы? Әгәр ул мине Куян белән бергә күрсә! Ул мине шундук кулга алачак бит!

Аю патша:

– Сыбызгы милиционер түгел ул. «Салават күпере» журналы Сыбызгысы!





«Җен кызы» (Зөлфәт).Рәссам В. Губская.

Урманны коткарып калу сезнең кулда, балакайлар! Барыгыз, күрегез! Кайткач һәммәсен дә сөйләрсез! Бетте! Китегез! Вәссәлам!

Төлке белән Куян сәяхәткә чыгып киттеләр.

Казан янына җитәрәк бер тау күрде болар. Куян аптырап сорады:

– Әллә Казан дигәннәре шул тау башында инде?

Төлке белдекле кыяфәттә:

– Ты чо!

– Нәрсә дип әйттең син?

– Урысча әйттем. Чөнки Казанда урысча сөйләшергә кирәк!

– Нишләп алай?

– Модасы шундый! Беләсең килсә!

– Ә мода нәрсә була?

– Модамы? – Төлке уйга калды. – Мода ул – кешеләр кия торган күлмәк-ыштан!

Куян тагын да катырак аптырап:


– Нигә, мәсәлән, безнең куяннарның телендә ыштанның бернинди катнашы да юк бит!

– Җитте! Лыгырдама! Ә теге тау, ул Җылантау булыр! – дип, Төлке кырт кисте дә сызгырып җибәрде. Шулчак ни булганын күрсәгез икән сез! Бар дөнья нурга күмелде, күктә салават күпере кабынды һәм... һәм... шул арада «Салават күпере»нең Сыбызгысы да чабып килеп җитте.

Ул урман кунакларын «Әкият» театрына алып та китте. Ә театрда аларны бер бәйләм чәчәк белән директор Роза апалары Яппарова, театр ветераны Галия Таһирова, баш режиссер Илдус абый Зиннуров каршы алдылар.







«Җылантау» (Т.Миңнуллин).

«Әкият»тә әкият башланды. Куян малае Җылантау белән кызыксынган иде бит әле. Иң беренче аларга Туфан абый Миңнуллин язган «Җылантау» әкиятен күрсәттеләр. Әлеге спектакльгә Илдус Зиннуров иҗат җылысын өргән булган икән. Сөбханалла! Ул әкиятне караганда урман кунаклары дөньяларын оныттылар. Анда Ай кызы Зөһрә дә бар, Алкын атлы малай белән Алтынай исемле гүзәл кыз һәм... җыланнар мыжгып тора! Юха җылан, Кара җылан, Патша җылан.

Әкият Казанның 1000 еллыгына багышланган.

Әнә Бартас бабай нәрсә ди: «Дөнья бит ул акылдан һәм матурлыктан яратылган. Кешеләр дә – акыл белән гүзәллекнең җимешләре».

Ә бер җылан үзенең патшасына нәрсә ди: «Тынычлык дип кычкырасыз, ә үзегез яныгызда чага торган Кара җылан асрыйсыз. Буар җыланнар тотасыз!»

Җыланнар арасында да Тынычлык юк икән, дип Төлке белән Куян бер-берсенә карашып алдылар. Бүген алар икесе янәшә утыралар һәм елмаеп кына сөйләшәләр иде.





Баш режиссер Илдус Зиннуров, композитор Мәсгудә Шәмсетдинова һәм драматург Туфан Миңнуллин.





Тәнәфес игълан иттеләр.

– Кара, кара, бу Кеше дигәннәрен тәнәфестә дә гел кәнфит суырып кына йөрмиләр икән. Әнә шигырь укыйлар. **(Алдагы битләрдә.)**



Разил Вәлиев шигырьләре

Шагыйрь Разил абыегыз Вәлиевнең әлеге шаян шигырьләре әкиятләр укырга, Курчак театрына барып кызыклы тамашалар карарга яратучы балаларның күңеленә аеруча хуш килер дип уйлыйбыз.



Мәҗлес

Әтәч коймага кунган,
Мәҗлес җыймакчы булган.

Утыра кунак көтеп,
Тәлинкәдә – бер бөртек.

Җыелганнар тавыклар,
Караганнар савытка.

Ә савытта – бер ярма...
Кикрикләре кабара.

Тавык явы башлана,
Әтәч алга ташлана.

Узып унбиш өтекне,
Чукып ала бөртекне.

Үзе шундый сөенә,
Җырлый «Сарман» көенә.

Тәлинкәсе бушын буш,
Тик чыкмады, ди, сугыш.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Песи төш күргән



Мич башында йоклаганда
Песи гаҗәп төш күргән.
Төшендә ул Африкада
Арыслан булып йөргән.

Теләсә кемнең өенә
Шакымый гына кергән.
Кемгә керсә дә, урынны
Биргәннәр аңа түрдән.

Арыслан караватында
Кичен йокларга яткан.
Төшендә ул мич башына
Кире әйләнеп кайткан.

Шул чагында песиебез
Куркып уянып киткән.
Песиме ул, арысланмы, –
Әле дә белми икән.



Безнең диңгез

Эштән кайткач,
Әти әйткән:
«Каян килде
Бу диңгез?
Моңа кадәр
Коры җирдә
Тора иде
Өебез.

Су эчендә
Өстәл, диван,
Зур шкаф
Утрау кебек.
Монда давыл
Булган, ахры,
Бөтен җирдә –
Ак күбек».

Әни күп уйлап тормаган,
Елмаеп, болай дигән:
«Диңгез түгел,
Бу, әтисе,
Улыбыз
Юган идән».

Спектакль тәмам булгач, Төлке белән Куян урамга һава суларга чыктылар. Янәшәдәге тауда балалар гөр килеп чана шуа. Һәммәсе тату, дус.

– Һе, – диде Төлке көрсенеп. – Мин гомерем буе сине куып азапланып, хәлдән таеп йөрдем. Ә болар ничек дус, тату. Шуңа күрә кешеләрнең урманнары да таза, төзек. Безнең урман кебек киселеп бетмәгән.

– Әйе шул, шулай шул, Төлке агай. Әйдә без дә шулай дус яшик әле, ә? – дип аның артыннан теркелдәде Куян.

– Һе, – диде, – Төлке. – Дус булсак, булырбыз. Түлке, әнә, теге кыз белән малай кебек култыклашып йөрмибез, яме. Алдан ук әйтеп куям!


– Чү, чү, – диде Куян. – Болар «Әкият» театрына кереп киттеләр бит.

Сыбызгы аңлатма бирде:

– Камыр батыр белән Сөмбел ләбаса ул. Хәзер «Камыр батыр» дигән спектакль уйнаячаклар. Әйдәгез, без дә керик.



«Камыр батыр» (С.Хөсни). Курчакларны сөйләштерүчеләр – Г.Габдрахманова, Ю.Чуктиев, Р.Фәйзуллина, М.Гайфуллин.



«Камыр батыр» спектакленең афишасы.



«Камыр батыр» спектакленнән күренеш.

Камыр батыр:

«Таңнан торып юлга чыгам,
Җилләр, каршы исмәгез.
Җилләр, каршыма исмәгез,
Өметемне кисмәгез!»

Куян:

– Нигә кайгыра ул Камыр батыр?

Төлке:

– Аның сөеклесен, Сөмбелне Сакалбай урлап киткән!

Куян:

– Ай, Аллам, харап булган икән! Әллә ярдәмгә урман-йорттан Аю патшаны чакырыйкмы икән, ә?!

Камыр батыр:

«Карыйм, карап туймыйм,
Чәчәк аткан бер гөл.
Чәчәк аткан бер гөл –
Син ул, Сөмбел».

Төлке:

– Ярата Камыр батыр Сөмбелне, ярата. Ә мәхәббәт ул барыннан да көчлерәк!

Төлке белән Куян кайтуга, Урман–йортта курчак театры оештырырга булдылар. Аннан соң кешеләр дә урманга агачларны кисеп-ботарларга килмәсләр иде. Театр карарга килерләр иде кешеләр урманга. Ял итәргә, җиләк, гөмбә җыя-җыя Урман театры спектакльләрен карарга!..

Чү, тукта! «Әкият»нең тарихын яхшы белергә кирәк бит моның өчен! Әгәр тарихыңны белмәсәң, син – манкорт. Чыңгыз Айтматов әсәре буенча куелган «Гасырдан озын көн» спектаклен үз күзләре белән күрделәр бит. Манкорт – бабаларның үткәнен, тарихын белмәгән кеше. Ул хәтта туган әнисен дә танымый! Бррр! Нинди куркыныч!..


Шулай итеп, Казан каласында һәвәскәр курчак эстрада театры «Беренче дәүләт интернациональ курчак театры»на әйләнеп китә. Һәвәскәрләр – 1932 нче елдан, профессиональ театр исә 1934 нче елдан эшли башлый. Театр «Петрушка октябрьдә» дигән беренче спектаклен күрсәтә. Театрның иҗат юлы әнә шулай башланып китә. Тукайның «Кәҗә белән Сарык» әкияте буенча беренче татарча пьеса языла.


Режиссер Л.Дьяченко.

«Казан турында кыйсса» (М.Гыйләҗев).



«Ана күзләре» (И.Зиннуров).



II МЕЖДУНАРОДНЫЙ ТЕАТРАЛЬНЫЙ ФЕСТИВАЛЬ

ГОСТИНЫЙ ДВОР

ДИПЛОМ

Татарскому государственному театру кукол «Экият» за участие в театральном фестивале спектакль Зульфат ЧУЛПАН - ЗВЕЗДА ВЗОЙДЕТ ... режиссер - постановщик Ильдус Зиннуров

ОРГКОМИТЕТ



Министерство культуры СССР

Всероссийское театральное общество

награждают

ДИПЛОМОМ

Казанский театр кукол

И. Зиннуров



II МЕЖДУНАРОДЕН ФЕСТИВАЛ НА КУКЛЕНИТЕ ТЕАТРИ ЗА ВЪЗРАСТНИ

ПИЕРО 2001

Стара Загора България 24 - 27 септември 2001

ДИПЛОМ

Журито на II Международен куклен фестивал

ПИЕРО 2001

състоял се в гр. Стара Загора от 24 - 27. 10 .2001 г.

НАГРАЖДАВА

Татарски държавен куклен театър Акият Казан Татарстан за участие със спектакъла „Цигани"

Стара Загора 27. 09. 2001

Председател на журито:

Курчак театрының күркәм эшләре хакында дипломнар сөйли.



Курчаклар ярдтучы абый



Сәләх Хөсни
(1912-1974)

Борын-борын заманда түгел, узган гасырда, 1912 елда Казанның Яңа Бистәсендә Мөхетдин Хөснетдинов гаиләсендә дүртенче бала булып бер малай дөньяга килә. Аңа Сәләх дип исем кушалар.

1915 елның кышында әнисе Мәфтуха Кабан күлендә кер чайкаганда бик каты салкын тидерә һәм бер ай үтәр-үтмәстән вафат була. Өч яше дә тулмаган Сәләхне һәм аның ике абыйсын – Фәттах белән Галәүне – 12 яшьлек апалары Фатыйма карап–тәрбияләп үстерә (ул газиз энекәшләренә бер үк вакытта Әни дә, Апа да була инде).

Беренче бөтендөнья сугышы, Октябрь революциясе, гражданнар сугышы кебек тетрәндергеч вакыйгалар Яңа Бистәгә зур үзгәрешләр алып килә. К.Насыйри исемендәге башлангыч мәктәп ачыла (Сәләх әүвәл шунда укый), пионер-комсомол хәрәкәте башлана.

1925-1928 елларда Яңа Бистәдә балалар һәм яшүсмерләр катнашында төрле бәйрәмнәр үткәрү гадәти хәлгә әйләнә. Ул бәйрәмнәрдә яшүсмер Сәләх бик теләп катнаша. Шул ук вакытта газеталарга хәбәрләр, шигырьләр, сценарийлар язу һәм сәхнәдә уйнау, чыгышлар ясау белән дә мавыга.

1931 елда 19 яшьлек сәләтле егетне Ленинградка (хәзерге Санкт-Петербург) Югары режиссерлар курсына укырга җибәрәләр. Аннан кайтып, җаваплы эшләрдә эшләгәннән соң, Сәләхне (бу вакытта инде ул Сәләх Хөсни дигән ир-егет, һөнәре буенча режиссер-драматург була) Татар дәүләт курчак театрына



19 яшьлек Сәләх Хөснетдиновның Ленинградта режиссерларның Югары курсында укыган чагы. 1931.

режиссер итеп билгелиләр. 1940елдан инде ул баш режиссер булып, 1965 елга кадәр әлеге театрда эшли.

Курчакларны һәм, әлбәттә, балаларны яратучы абый, дәртләнеп-канатланып, яңадан-яңа, кызыклы-маҗаралы әкияти пьесалар иҗат итәргә тотына. Аның «Дутан батыр», «Камыр батыр» кебек дистәләгән тамашалары балалар күңеленә бик хуш килә.

Театрдагы уңышлы хезмәтләре өчен Сәләх Хөсни Татарстанның атказанган артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә лаек була.

«Эш күрсәткән ирне ил онытмас», – диләр. Тарихта якты эз калдырган Сәләх Мөхетдин улы Хөсни исеме дә халкыбыз күңелендә мәңге яшәр.



1



2



3

1. Курчаклар яратучы абыйның тууына 90 ел тулган көннәр. С.Хөснинең улы Роберт һәм кызы Дамирә театрның баш режиссеры Илдус Зиннуров янында. 2002.

2. С.Хөсни оныкларының балалары Лира (уңда), Рөстәм һәм Линара. Курчак театрында бабалары әсәре буенча куелган «Камыр батыр» спектаклен караган көнне төшкән сурәт. 2002.

3. Казанның Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә 2002 елның 7 октябреннән 2003 елның 30 гыйнварына кадәр С.Хөснинең тормышын, иҗатын һәм сәхнә эшчәнлеген яктырткан күргәзмә эшләде.



«Әкият» театрына һич кенә дә әкият дип кенә карамагыз! Тау күчерергә сәләтле Алып батыр «Әкият» театрын дөнья буйлап сәяхәткә дә алып чыга икән.

1994 нче елда ике мәртәбә Германиядә булганнар, аннан соң өч тапкыр Төркиядә. Франция, Болгария фестивальләре! Дөнья буйлап йөргән театр ул «Әкият».

Илдус Зиннуров «Ана күзләре» исемле спектаклен Польшада «Ломжа» курчак театрында поляк артистлары белән дә куйды.

Менә шуның белән Урман әкияте дә тәмам, балалар! Тфү, тфү, телебезне корт чаксын! Ничек тәмам булсын! «Әкият» бар бит әле безнең! «Әкият» театры булгач, анда көн саен яңа әкият туып торачак, әлбәттә. Ышанмыйсызмы? Ышанмасагыз, үзегез килегез дә карагыз, яме. Кар таулары артында түгел ул. Казан каласында. «Сим-Сим, ач ишекне!» дип әйтсәң, ишекләре шундук ачылып китәчәк!..

«Сим-Сим, ач ишекне! Без киләбез».

Курчак театрының адресы: *420107, Казан, Луковский урамы, 21 нче йорт.*
Телефоннар: **38–94–71, 38–90–44, 38–92–72**



«Гали баба һәм кырык карак» спектакленнән күренеш.



Оренбургта барган «Гостиный двор» фестивален йомгаклау көне. Р.Яппарова, Россиянең халык артисты, режиссер Р.Исрафилов, И.Зиннуров. 2003.

Илдус абый Зиннуров Германиядә куелган «тимер кеше»гә җан өрмәкче була, ахрысы.





Рязань шәһәрендә үткәрелгән Халыкара курчак театрлары фестивале вакытында: Р.Яппарова, Воронеж курчак театрының баш режиссеры В.Вольховский, И.Зиннуров. 2003.

Сәләвәт күпере

2(167) — 2004

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.

1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.

Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Фәрит МУЛЛАХМӘТ һәм Фидель ХӘСӘНОВ коллажы.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: ck-sxn@newmail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиесе.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 20.02.2004 ел.
Басарга кул куелды 20.02.2004 ел.
Кәгазь форматы 60х100 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 13001 данә. Заказ Э-108.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



Ләбиб Лерон

Курчак театрында

Курчаклар сөйләшә белә,
Курчаклар уйный белә.
Алар да безнең шикелле
Шаяра, уйный, көлә...

Үзләренә кунак булып,
Җыйналып килсәк әгәр,
Барчабызны шаккаттырып,
Тамаша күрсәтәләр.

Матур итеп, моңлы итеп
Җыр җырлыйлар курчаклар...
Кушылып җырлыйсы килә
Курчакларга шул чакта.

Дию, Кәрлә, Шүрәле дә,
Хан кызы да бар монда...
«Кайда!» – димә, беләсең ич –
Курчак театрында!

*«И, кызык Шүрәле!..» (Г. Зәйнашева).
Артистлар: Рәмзия Фәйзуллина, Ришат Гыйздәтуллин.*